**Программаның билгеләнеше:**

«Сүз остаханәсе» дигән дәрестән тыш эшчәнлек программасы укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, 5-9 нчы сыйныф укучылары өчен 34 сәгатькә төзелде.

**Төп эш формалары**:

- әңгәмә;
- эзләнү, тикшеренү эшләре алып бару;
- иҗади язма эшләр үтәү һәм яклау;
- «Ми штурмы» методы.

**Кулланылган технологияләр**:

- информацион-коммуникатив технология;
- хезмәттәшлек технологиясе;
- креатив технология;
- иҗади үсеш технологиясе.

**Программаның структурасы:**

Программа 5 бүлектән тора һәм алар темаларга бүленгән.

Программада теоретик материалның гамәли эшчәнлек белән үрелеп баруы тәэмин ителә. Гамәли күнегүләр алган белемнәрне ныгытырга һәм укучыларның теоретик материалларны үзләштерү дәрәҗәсен контрольдә тотарга ярдәм итә. Укытучы аларны үзе теләгәнчә үзгәртә дә ала.

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

-активлыкка, иҗади фикер йөртүгә, акыл һәм рухи эшчәнлеккә өйрәтү, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;

-үзең белән идарә итүгә юнәлдерелгән белем һәм күнекмәләрне тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;

-грамоталылыкны үстерү;

-әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

**Регулятив УУГ**

- фикерләү креативлыгы, төрле иҗади эшләр язганда активлык;

-мөстәкыйль рәвештә эшчәнлекнең проблемасын (тема),формалаштыру;

-проблеманы аңлый белү, гипотеза чыгару, материалны төзү, үз фикереңне раслау өчен дәлилләр сайлый белү, телдән һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;

-укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү;

**Танып белү УУГ**

-укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә бәяләү, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен бәяләве;

- мөстәкыйль рәвештә төрле текстларны укый, яза белү, өстәмә материалларны таба һәм тиешле урында куллана белү;

-төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегенд куллана белү;

-үзенә кирәкле мәгълүматны төрле формада бирелгән чыганаклардан туплау;

-сүзлекләр белән файдалану;

**Коммуникатив УУГ**

-төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;

-бер фикер кабул иткәнчә, төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
-укылган, тыңланган мәгълүмат буенча сораулар бирә алу;
-үз эшен контрольдә тоту, иптәшләренә ярдәм итү;
-коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
-бергәләп эшләгәндә, бердәм карар кабул итә белү;
-текст буенча сораулар куя белү.

## Программаның эчтәлеге

**I. Морфология (8 сәгать).**

**Сүзләрне төркемләү.** Предметларны төркемләгәндә, "Тартып алышлы" уены уйнала. Бу уен укучыларны телнең төрле грамматик фактларын чагыштыра, капма-каршы куя, уртак һәм аермалы якларын таба белергә өйрәтә.

**"Нәтиҗәне белүдән түгел, фикер йөртеп, нәтиҗәгә килүдән башлыйк әле".**

Ялгызлык исемнәр белән уртаклык исемнәр ничек аерыла? Ялгызлык исемнәр ярдәм итмәсә? Кушамат нигә кирәк? дигән проблемалы сорауларга җавап эзлиләр.

**"Тылсымлы квадратлар".** Исемнәрдән кроссвордлар төзиләр.

**"Сыйфатлы циферблат" уены.** Ике сыйфат (мәсәлән, ак, җиңел) әйтелә. Бирелгән сыйфатларның икесенә дә туры килгән предмет уйларга тәкъдим ителә.

**Күп предметта бер билге, бер предметта күп билге.** Бер предметка туры килә торган сыйфатлар, бер сыйфатка туры килә торган исемнәр уйлыйлар.

**Бер предметта күпртөрле эш, күп предметта бертөрле эш.** Бер предметка туры килә торган фигыльләр, бер фигыльгә туры килә торган исемнәр уйлыйлар.

**"Сүзгә рифма уйла", "Ахырын әйт" уеннары.** Бирелгән сүзләргә рифмалар уйлыйлар, шигырь юлларын укытучы башлап бирә, ә балалар аны дәвам итә.

**"Без шигырь язабыз".** Бу **эшне** башкарганда укучы мөстәкыйль фикер йөртә, эзләнә, яңалык таба, нәтиҗә ясый һәм дәрестә алган белемнәрен ныгыта.

**II. Синтаксис (8 сәгать).**

**Сөйләм культурасы.** Туган телне яратырга һәм нечкә итеп тоярга, аның сүз байлыгын дөрес файдаланырга өйрәтү дәресе. Монда текст редакцияләргә өйрәтелә, "Microsoft Word" программасында эшләү күнекмәләрен үстерелә. Без һәрвакыт матур итеп, саф татарча сөйләшүчеләргә сокланабыз. Моңа ирешү өчен, телне бик яхшы белергә, тоярга, гасырлар буе тупланып килгән сүз байлыгын дөрес файдаланырга кирәк. Кайда гына укысаң да, эшләсәң дә, кешеләр белән сөйләшә белү, дөрес язу бик мөһим.

**Фикерне икенче төрле әйтү юллары.** Җөмлә әйтелә, мәсәлән, «Быел җәй җылы булыр». Бу җөмләне, мәгънәсен үзгәртмичә, икенче төрле әйтергә кирәк.

**Алгоритм буенча сөйләм төзү.** Цицерон алгоритмын кулланырга мөмкин. «Кем-нәрсә, нәрсә белән, ни өчен, ничек, кайчан?». Бу бирем эзлекле фикерләү сәләтен үстерә.

**Хикәягә баш (исем) уйлау, кыскарту.** Бирелгән хикәягә исем уйлап табалар, кыскарту юлларын эзлиләр.

**"Сезне нәрсә шаккаттырыр?", "Чит планетадан килгән кеше сораулары" дигән уеннар.** Ниндидер бер ситуация сайлана, мәсәлән, ишек алдында, концертта, бассейнда, урамда, мәктәптә. Укучыларга берәр кызыклы хәл турында сөйләргә тәкъдим ителә.». «Чит планета кешесе» класс бүлмәсендәге теләсә нинди предметны сайлап ала һәм аны икенче планетада үзе дә куллана алырлык итеп сораулар бирә.

**Картина буенча тасвирламалы хикәя.** Картиналар – балаларда коммуникатив сөйләм күнекмәләре булдыруда нәтиҗәле чара, алар укучыларның сөйләм активлыгын, фикер йөртү, танып-белү эшчәнлеген үстерә, игътибар һәм күзәтүчәнлекне дә арттыра.

**III. Орфография ( 7 сәгать).**

**“Алфавит каласы”.** Татар алфавитындагы хәрефләр санын, аларның урнашу тәртибен, хәреф исемнәрен һәм исемнәренә аваз мәгънәләрен белүнең мөмкинлеге турында мәгълүмат алалар.Тормышта алфавитның тоткан ролен билгелиләр.

**Бу предмет исемнәрен нәрсә берләштерә?** Предметларның берләштерүче уртак сыйфатларны билгелиләр, шундый биремнәр уйлап табалар.

**“Орфографик лото” уены.** Лото уены орфографик хаталарны кисәтү максатыннан үткәрелә. Укучылар, бирелгән сүздәге хәрефләргә нигезләнеп, лото уены уйныйлар.

**Метаграммалар төзү.**Табышмак итеп бирелгән сүз, бер хәрефен үзгәртү белән, бүтән сүзгә әйләнә.Укучылар, кагыйдәгә нигезләнеп, метаграммалар төзиләр.

**Анаграмма төзү.** Хәрефләрне алыштырып, яңа сүз яки сүзтезмә уйлап табыла.Укучылар, кагыйдәгә нигезләнеп, анаграммалар төзиләр.

**“Мин нәшриятчы, газета мөхәррире”.** Бирелгән текстлардан хаталарны төзәтеп, язылган хикәя, шигырьләрне дөрес итеп урнаштырыралар.

**IV. Лексика һәм фразеология ( 9 сәгать).**

**Тылсымлы тел дөньясы.** Дәрес сорау-җавап һәм практик юнәлештә алып барыла. Башта әзер ребуслар һәм кроссвордлар тәкъдим ителә, аннары укучылар үзләре сканворд төзеп карый. Бу эшне алар бер-берсенә ярдәмләшеп, киңәшеп башкаралар. Тылсымлы тел дөньясында кайныйлар.

**Гади билгеләре буенча предметларны табу.** Предметларны иң гади билгеләре буенча табу уены табышмаклар уены кебек оештырыла. Һәр балага биремле бер карточка һәм җавап язылган 6 каплагыч карточка бирелә.

Тәфсилле билгеләре буенча предметларны табу. Бу уен укучыларның сөйләмен үстерүгә, сүзлек хәзинәсен арттыра. Тәфсилле билгеләрне күрсәтү күзәтүчәнлек, логик фикерләү, чагыштыра белү сәләтен үстерә.

**Охшаш һәм аермалы яклар.** Ике әйбернең, мәсәлән, су һәм сөт, самолет һәм поездның аермалы һәм охшаш яклары табыла.

**Логогрифлар төзү.**Табышмак ителгән сүздәге иҗекләрне, хәрефләрне икенче бер иҗек һәм хәрефләр белән алыштыру аркасында яки сүз эчендә урыннарын күчереп кую нәтиҗәсендә бүтән сүз килеп чыга. Укучылар, кагыйдәгә нигезләнеп, логогрифлар төзиләр.

**Шарадалар төзү.**Табышмак итеп алынган сүзнең һәр кисәге мөстәкыйль сүз була ала. Укучылар, кагыйдәгә нигезләнеп, логогрифлар төзиләр.

**Фразеологизмнар, аларны төркемләү, матур әдәбиятта һәм публицистикада кулланылышы.** Фразеологизмнар, аларның төрләре, матур әдәбиятта һәм публицистикада, җанлы сөйләм дә кулланылышы. Синонимик һәм антонимик фразеологизмнар. Фразеологик калькалар. Тексттан фразеологизмнарны табалар, мәгънәсен ачыклыйлар. Фразеологизмнарны сөйләмдә кулланалар.

**“Без табышмак язабыз”.** Балаларның зирәклеген, күзәтүчәнлеге үстерелә. Табышмакларның үзенчәлекләрен аңларга, тиз фикер йөртергә өйрәнәләр.

**V. Системалаштыру. Фәнни тикшеренү эшчәнлеге (3 сәгать).**

**Фәнни - тикшеренү эшенең төп төшенчәләре** Аспект, гипотеза, дедукция, идея, индукция, категория, концепция, төп (ачкыч) сүз, тикшеренү ысулы (методы), фәнни танып белү ысуллары турындагы өйрәтмә, фәнни тәртиплек, фәнни тема, фәнни теория, фәнни тикшеренү, фәнни танып белү, фәнни факт, күзәтү (обзор), тикшеренү объекты, тикшеренү предметы, принцип, проблема, теория, фикри нәтиҗә (сөземтә).

**Фәнни – тикшеренү алып баруның гомуми схемасы.** Сайлап алынган теманың актуальлеге,

максат һәм тикшеренүнең конкрет бурычларын куела, тикшеренүнең объект һәм предметын билгеләнелә, тикшеренү эшен алып бару ысуллары һәм методикасын (эшкә өйрәтү системасы) сайланыла, тикшеренү процессы, тикшеренү нәтиҗәләре буенча фикер алышына , алынган нәтиҗәләргә бәя бирелә.

**Логик кануннар һәм кагыйдәләрне куллану.** Тигезлек кануны, капма-каршылык кануны, өченче вариантны кабул итмәү кануны, кирәк дәрәҗәдә нигезлелек кануны, логик билгеләмәләр төзү кагыйдәләре.

**Мәгълүмат эзләү.** Мәгълүмат төрләре (обзор-күзәтү, реферaтив, сигналлы, белешмәле).

**Фәнни – тикшеренү эше алып баруның этаплары.** Тема сайлау.Фәнни - тикшеренү эшенең планы. Фәнни чыганаклар (әдәбият) белән эш. Фәнни төшенчәләр (терминнар) аппараты белән эш. Тәҗрибә - эксперименталь эш.

**Фәнни - тикшеренү эшенең нәтиҗәләре белән таныштыру.** Презентация ясау методикасы.Чыгыш ясарга әзерлекнең психологик аспекты. Чыгышка, докладка таләпләр. Чыгыш ясау һәм дискуссия алып бару тәртибе (культурасы: этикет кагыйдәләрен саклау, оппонентларга мөрәҗәгать итү, сорауларга җавап бирү, йомгаклау сүзе.)

**Укыту-тематик план**

| **№** | **Тема** | **Методлар** | **Көтелгән нәтиҗә** |
|---|---|---|---|
| 1. | Морфология | Логик фикерләү методлары<br>Иҗади фикерләү методлары:<br>а) яңа материалны проблемалы тасвирлау, “Ми штурмы” методы;<br>б) өлешчә –эзләнүле метод;<br>в) теоретик материалны модельләштерү. | Логик фикерләү дәрәҗәсен үстерү.<br>Иҗади фикерләү дәрәҗәсен сәләтен үстерү |
| 2. | Синтаксис | Логик фикерләү методлары:<br>а) төшенчәләр буенча модельләштерү;<br>б) төшенчәләрне формалаштыру.<br>Иҗади фикерләү методлары:<br>а) яңа материалны проблемалы тасвирлау, “Ми штурмы” методы;<br>б) өлешчә –эзләнүле метод;<br>в) эзләнү, тикшеренү методлары;<br>г) фәнни – популяр әдәбият, текстлар белән эш.<br>Ассоциатив фикерләү методлары:<br>а) чагыштыру, гомумиләштерү методлары;<br>б) танып-белү эшчәнлеген көчәйтү.<br>Үстерешле фикерләү методлары:<br>а) план төзү;<br>б) проблемалы ситуацияне чишү. | Логик фикерләү дәрәҗәсен үстерү.<br>Иҗади фикерләү дәрәҗәсен сәләтен үстерү.<br>Ассоциатив фикерләү дәрәҗәсен үстерү<br>Үстерешле фикерләү дәрәҗәсен үстерү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Орфография | Логик фикерләү методлары:<br>а) төшенчәләр буенча модельләштерү;<br>б) төшенчәләрне формалаштыру.<br>Иҗади фикерләү методлары:<br>а) яңа материалны проблемалы тасвирлау;<br>б) өлешчә –эзләнүле метод;<br>в) эзләнү, тикшеренү методлары;<br>г) фәнни – популяр әдәбият, текстлар белән эш. | Логик фикерләү дәрәҗәсен үстерү.<br><br>Иҗади фикерләү дәрәҗәсен сәләтен үстерү. |
| 4 | Лексика һәм фразеология | Күрсәтмәле-тәэсирле фикерләү методлары:<br>а) гамәли эш;<br>б) таблица һәм схемалар төзү.<br>Ассоциатив фикерләү методлары:<br>а) чагыштыру, гомумиләштерү методлары;<br>б) танып-белү эшчәнлеген көчәйтү. | Күрсәтмәле-тәэсирле фикерләү дәрәҗәсен үстерү.<br>Ассоциатив фикерләү дәрәҗәсен үстерү. |
| 5 | Системалаштыру (Фәнни тикшеренү эшчәнлеге) | Системалы фикерләү методлары:<br>а) проектлар эшләү;<br>б) фәнни конференцияләрдә катнашу. | Системалы фикерләү дәрәҗәсен үстерү. |

**Календарь-тематик план**

| № п/п | Тематик бүленеш | Сәг. саны | **Укучылар эшчәнлеге** | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | план | факт |
| | **Морфология** | | | | |
| 1.<br>2. | Сүзләрне төркемләү.<br>Морфология дөньясында. “Нәтиҗәне белүдән түгел, фикер йөртеп, нәтиҗәгә килүдән башлыйк әле”. | 1<br>1 | Таблица һәм схемалар төзү<br>, модельләштерү | 08.09<br><br>15.09 | |
| 3. | “Тылсымлы квадратлар”<br>Исемнәрдән кроссвордлар төзү | 1 | Ребуслар, кроссвордлар чишү | 22.09 | |
| 4. | “Сыйфатлы циферблат” уены | 1 | “Ми штурмы” методы, уеннар | 29.09 | |
| 5. | Күп предметта бер билге, бер предметта күп билге | 1 | Яңа материалны проблемалы тасвирлау | 6.10 | |
| 6. | Бер предметта күпртөрле эш, күп предметта бертөрле эш | 1 | Чагыштыру, гомумиләштерү | 13.10 | |
| 7. | “Сүзгә рифма уйла”, “Ахырын әйт” уеннары | | “Ми штурмы” методы, уеннар | 20.10 | |
| 8. | “Без шигырь язабыз” | 1 | Гамәли эш | 27.10 | |
| | **Синтаксис** | | | | |
| 9. | Сөйләм культурасы. | 1 | Эзләнү элементлары белән практикум | 17.11 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 10 | Тизәйткеч-телебезне төзәткеч | 1 | Уеннар | 24.11 | |
| 11. | Аралашу шартларына тәңгәл рәвештә укыган, тыңлаган, күргән мәгълүмат эчтәлеген сайлап алып, кыскача һәм җентекләп сөйләү . Фикерне икенче төрле әйтү юллары | 1 | Чагыштыру, гомумиләштерү Уеннар. "Әйе-юк димәскә, ак-карага тимәскә" | 1.12 | |
| 12. | Алгоритм буенча сөйләм төзү | 1 | Танып-белү эшчәнлеген көчәйтү | 8.12 | |
| 13. | Хикәягә баш (исем) уйлау, кыскарту | 1 | Гамәли эш | 15.12 | |
| 14. | "Сезне нәрсә шаккаттырыр?", "Чит планетадан килгән кеше сораулары" дигән уеннар | 1 | "Ми штурмы" методы, уеннар | 22.12 | |
| 15. | Картина буенча тасвирламалы хикәя | 1 | "Ми штурмы методы" Гамәли эш | 12.01 | |
| 16 | Бишек җырларында эндәш сүзләр | 1 | Тикшеренү эше | 19.01 | |
| **Орфография** | | | | | |
| 17. | "Алфавит каласы" | 1 | Таблица һәм схемалар төзү, модельләштерү | 02.020 | |
| 18. | Бу предмет исемнәрен нәрсә берләштерә? | 1 | Өлешчә эзләнү | 09.02 | |
| 19. | "Орфографик лото" уены | 1 | "Ми штурмы" методы, уеннар | 16.02 | |
| 20. | Метаграммалар төзү | 1 | Гамәли эш | 23.02 | |
| 21. | Анаграмма төзү | 1 | Гамәли эш | 2.03 | |
| 22. | "Мин нәшриятчы, газета мөхәррире" | 1 | Эзләнү, тикшеренү | 9.03 | |
| 23 | Балалар матбугаты дөньясында | 1 | Матбугат ру сайтына виртуаль экскурсия | 16.03 | |
| **Лексика һәм фразеология** | | | | | |
| 24. | Тылсымлы тел дөньясы | 1 | Ребуслар, кроссвордлар чишү | 6.04 | |
| 25. | Гади билгеләре буенча предметларны табу | 1 | Төшенчәләр буенча модельләштерү, "Ми штурмы" методы | 13.04 | |
| 26. | Тәсфилле билгеләре буенча предметларны табу | 1 | Таблица һәм схемалар төзү | 20.04 | |
| 27. | Охшаш һәм аермалы яклар | 1 | "Ми штурмы" методы, уеннар | 27.04 | |
| 28. | Логогрифлар төзү | 1 | Гамәли эш | 4.05 | |
| 29. | Шарадалар төзү | 1 | Гамәли эш | 11.05 | |
| 30. | Фразеологизмнар, аларны төркемләү, матур әдәбиятта һәм публицистикада кулланылышы | 1 | Фәнни – популяр әдәбият, текстлар белән эш | 18.05 | |
| 31. | "Без табышмак язабыз" | 1 | Гамәли эш | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 32. | Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел | 1 | КВН | | |
| **Системалаштыру**<br>**(Фәнни тикшеренү эшчәнлеге)** | | | | | |
| 33. | Фәнни тикшеренү эшләренең төп төшенчәләре Фәнни тикшеренү эшенең этаплары. | 1 | Гамәли эш | 24.05 | |
| 34 | "Татарча да яхшы бел" . Фәнни-тикшеренү эшен яклау | 1 | Гамәли эш | 25.05 | |

## Укытучы өчен әдәбият исемлеге


1. С.Г.Вагыйзов, Р.Г.Вәлитова. «Кызыклы грамматика».Казан «Мәгариф» 2009
2. Саттаров Г.Ф. Татар телендә шәхескә олылап эндәшү. Казан. Татарстан китап нәшрияты.
3. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Казан. "Мәгариф" нәшрияты, 2005.
4. Сәлимов Х.Х. Татар теленең орфоэпик сүзлеге. Чаллы, "Камаз" нәшрияте, 2005.
5. Хангилдин В.Н. Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре. Казан. "Мәгариф" нәшрияты.
6. Н.С. Гыймадиева «Дәрестә һәм дәрестән соң» Казан, 2004.
7. С.М. Трофимова «Татар теле һәм әдәбияты укытучысына» Казан, 2005.
8. Ф.С. Сафиуллина «Учат таблицы и схемы» Казан.
9. Л.К. Хөснетдинова «Әдәбият укыту мәсъәләләре» Яр Чаллы, 2009.
10. Хангилдин В.Н. Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре. – Казан: Тат.кит.нәшр.
11. Юсупов Р.А. Укучыларда сөйләм культурасы тәрбияләү. – Казан: Тат.кит.нәшр.
12. С.Г.Вагыйзов "Кызыклы грамматика" "Мәгариф" нәшрияты.

**Укучылар өчен әдәбият**

1. Вәлиуллина Р.Г., Нигмәтҗанова Ф.М. Эшлекле татар теле.- Казан. 2004.
2. Татар теленең орфографик сүзлеге. Казан. Татарстан китап нәшрияте.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 том. Татарстан китап нәшрияте, Казан.
4. Русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр.
5. Вакытлы матбугат (“Салават күпере”, “Ялкын”, “Мәгариф” журналлары, “Көмеш кыңгырау”, “Сабантуй” журналлары һ.б..)